| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ<br>«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»<br>ЧИСТОПОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ** | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>**ЧИСТАЙ<br>ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ** |
|---|---|---|

***Решение*** ***Карар***

**24.05.2023 ел** **Чистай шәһәре** **№22/2**

2023 елга һәм 2024-2025 еллар
план чорына Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
“Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге
бюджетына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе Карманова Наталья Анфиногентовнаның «2023 елга һәм 2024-2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына үзгәрешләр кертү турында»гы докладын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының 2023 елга һәм 2024-2025 еллар план чорына «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2022 елның 15 декабрендәге 18/2 номерлы Чистай шәһәр Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. 2023 елга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 212867,7 мең сум күләмендә;

2) Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 216135,9 мең сум күләмендә.

3) Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгының иң чик күләме 3268,2 мең сум күләмендә.»

1.2. 1 нче кушымта «2023 елга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының 2023 елга һәм 2024 - 2025 еллар план чорына «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты турында» Татарстан Республикасы

Чистай шәһәр Советы карары белән 2022 елның 15 декабрендәге 18/2 номерлы карары белән әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә.

1.3. 3 нче кушымта «2023 елга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетының фаразлана торган керемнәре күләме» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының 2023 елга һәм 2024 - 2025 еллар план чорына «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 2022 елның 15 декабрендәге 11/2 номерлы карарына ярашлы рәвештә әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

1.4. 5 нче кушымта «2023 елга Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының 2023 елга һәм 2024 - 2025 еллар план чорына «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты турында» Татарстан Республикасы Чистай шәһәре Советының 2022 елның 15 декабрендәге 11/2 номерлы карарына, барлык көчешләрне исәпкә алып, әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә.

1.5. 7 нче кушымта «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2023 елга чыгымнарны классификацияләү төрләре төркемнәре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре) буенча бүлү» Чистай шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең 2023 елга һәм 2024-2025 еллар план чорына бюджеты турында» 2022 елның 15 декабрендәге 18/2 номерлы карарына барлык көчешләрне исәпкә алып, әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә редакциядә бәян итәргә.

1.6. 10 нчы кушымта «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына 2023 елда Чистай муниципаль районы бюджетыннан күчерелә торган бюджетара трансфертлар» «2023 елга, 2024 - 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты турында» Татарстан Республикасы Чистай шәһәр Советының 2022 елның 15 декабрендәге 18/2 номерлы карарына ярашлы рәвештә әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

1.7. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарын түләүсез керемнәр хисабына 21237,6 мең сум күләмендә арттырырга, шул исәптән:

«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Башкарма комитеты " 814 ведомствосы буенча 21237,6 мең сум күләмендә;

1.8. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарын Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге акчалары хисабына «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Башкарма комитеты» 814 ведомствосы буенча 199,7 сум күләмендә арттырырга.

1.9. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарын үз акчаларының 01.01.2023 елга калган өлеше исәбенә 1728,2 мең сумга арттырырга, шул исәптән:

«Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр башкарма комитеты» 814 ведомствосы буенча 1631,4 мең сум күләмендә;

813 ведомство буенча «Чистай шәһәр Советы» 96,8 мең сум күләмендә.

1.10. «Чистай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» ведомствосы буенча Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарын “Резерв фонды” 0111 бүлекчәсе буенча 174,5 мең сум күләмендә киметергә.

1.11. Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарын «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр башкарма комитеты» 814 ведомствосы буенча 174,5 мең сум күләмендә арттырырга.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында яисә «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет һәм фаразлау, сәнәгать һәм эшкуарлык буенча даими депутат комиссиясенә (Н.В. Миңнегалиев) йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов